ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МЕНДЕЛЕЕВСК МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БӘЗӘКӘ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕНЕҢ ТАТАР ТӘКӘШЕ ТОРАК ПУНКТЫНДА
ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ

КАРАР

20 ноябрь 2024 ел № 10

2025 елда Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Бәзәкә авыл җирлегенең Татар Тәкәше торак пунктында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьясы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, “Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Бәзәкә авыл җирлегенең Татар Тәкәше торак пунктында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләү турында” Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Бәзәкә авыл җирлеге башлыгының 2024 елның 9 ноябрендәге 12 номерлы карары нигезендә, Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Бәзәкә авыл җирлегенең Татар Тәкәше авылы гражданнар җыены

КАРАР КЫЛДЫ:

1. 2025 елда Менделеевск муниципаль районы Бәзәкә авыл җирлегенең Татар Тәкәше авылында яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 1500 сум күләмендә, I-II төркем инвалидлардан, Бөек Ватан сугышында катнашучылардан һәм аларга тиңләштерелгәннәрдән , югары һәм урта уку йортларының көндезге бүлегендә укучы студентлардан бер тапкыр түләүне 50% ка киметеп, 750 сум күләмендә, махсус хәрби операциядә катнашучылар һәм аларның гаилә әгъзаларын түләүдән азат итеп, үзара салым акчаларын кертергә.
2. Алынган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү өчен түбәндәге ихтыяҗларга юнәлтергә:

   -Торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмияткә ия булган автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту; (Татар Тәкәше авылына юлларны кардан чистарту)

   - Су белән тәэмин итү чыганакларыннан су алуны, аны чистартуны, транспортировкалауны һәм халыкка су бирүне тәэмин итә торган су белән тәэмин итү һәм су агызу системаларын, су җыю манараларын, скважиналарны һәм башка инженерлык корылмаларын проектлау, төзү һәм ремонтлау, алар сүүткәргеч торбалар сатып алу, Татар Тәкәше авылының сүүткәргеч торбаларын урнаштыру)
3. Әлеге карарны Бәзәкә авыл җирлегенең махсус җиһазландырылган мәгълүмат стендларына урнаштырып халыкка җиткерергә, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында бастырып чыгарырга http://pravo.tatarstan.ru һәм Менделеевск муниципаль районының рәсми сайтында « Бәзәкә авыл җирлеге» бүлегендә урнаштырырга http://mendeleevsk.tatarstan.ru

Гражданнар җыенында рәислек итүче
Бәзәкә авыл җирлеге башлыгы И.И. Кәшәфетдинов